| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2024 Баулы шәһәре №191

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы "Исергәп авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар, (иҗтимагый фикер алышулар) үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының "Исергәп авылы җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны билгеләргә (алга таба - Проект).

2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру вакытын 2024 елның 25 декабреннән 9 гыйнварына кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралачак Проект экспозициясен 2024 елның 25 декабрендә ачарга.

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Баулы районы, Исергәп авылы, Совет урамы, 86 йорт адресы буенча;

- Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

4.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы экспозицияне барып карау режимы түбәндәге адрес буенча: Баулы муниципаль районы, Исергәп авылы, Совет урамы, 13 йорт, эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 8.30 - 11.30 һәм 13.30 - 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2024 елның 10 декабреннән 24 декабрьгә кадәр, Мәскәү вакыты белән эш көннәрендә 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 дан 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

- иҗтимагый фикер алышулар оештыручыга, язма рәвештә, түбәндәге адрес буенча: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб;

- Bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетын (алга таба - иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы) билгеләргә.

7. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышуларны уздыру башлану турында хәбәр итүне, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Исергәп авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге, Исергәп авылы җирлеге Башкарма комитеты бинасында, 2024 елның 25 декабренннән 9 гыйнварына кадәр, эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30-11.30, 13.30-16.00 сәгатьләрдә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы — И.И. Гозәеров